**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# О Республиканской межведомственной комиссии по обеспечению реализации приоритетного проекта «Формирование комфортной городской среды»

В целях обеспечения реализации приоритетного проекта «Формирование комфортной городской среды» на территории Республики Татарстан, во исполнение постановления Правительства Российской Федерации от 10 февраля 2017 года № 169 «Об утверждении Правил предоставления и распределения субсидий из федерального бюджета бюджетам субъектов Российской Федерации на поддержку государственных программ субъектов Российской Федерации и муниципальных программ формирования современной городской среды» **постановляю:**

1. Образовать Республиканскую межведомственную комиссию по обеспечению реализации приоритетного проекта «Формирование комфортной городской среды».

2. Утвердить Положение о Республиканской межведомственной комиссии по обеспечению реализации приоритетного проекта «Формирование комфортной городской среды» (приложение № 1) и ее состав (приложение № 2).

3. Кабинету Министров Республики Татарстан:

обеспечить своевременную подготовку материалов к заседаниям Республиканской межведомственной комиссии по обеспечению реализации приоритетного проекта «Формирование комфортной городской среды»;

привести свои правовые акты в соответствие с настоящим Указом, а также принять иные решения, необходимые для его реализации.

4. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ

**Президент
Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
29 мая 2017 года
№ УП-448

Приложение № 1
к Указу Президента
Республики Татарстан

от «29» мая 2017 года

№ УП-448

# Положение
# о Республиканской межведомственной комиссии по обеспечению реализации приоритетного проекта «Формирование комфортной городской среды»

## I. Общие положения

1. Республиканская межведомственная комиссия по обеспечению реализации приоритетного проекта «Формирование комфортной городской среды» (далее – Комиссия) является межведомственным коллегиальным органом, образованным во исполнение постановления Правительства Российской Федерации от 10 февраля 2017 года № 169 «Об утверждении Правил предоставления и распределения субсидий из федерального бюджета бюджетам субъектов Российской Федерации на поддержку государственных программ субъектов Российской Федерации и муниципальных программ формирования современной городской среды» для осуществления контроля над ходом выполнения приоритетного проекта «Формирование комфортной городской среды» (далее – Приоритетный проект) и координации его реализации на территории Республики Татарстан.

2. Комиссия в своей деятельности руководствуется Конституцией Российской Федерации, федеральными законами, иными нормативными правовыми актами Российской Федерации, Конституцией Республики Татарстан, законами Республики Татарстан и иными нормативными правовыми актами Республики Татарстан, а также настоящим Положением.

## II. Основные задачи и функции Комиссии

3. Основными задачами Комиссии являются:

а) осуществление контроля над ходом выполнения Приоритетного проекта и координации его реализации на территории Республики Татарстан;

б) осуществление контроля и координации выполнения государственной программы Республики Татарстан по обеспечению реализации приоритетного проекта «Формирование комфортной городской среды» (далее – Государственная программа) и муниципальных программ формирования современной городской среды (далее – муниципальные

программы), в том числе конкретных мероприятий в рамках указанных программ;

в) осуществление контроля и координации исполнения Республикой Татарстан условий соглашения, заключенного с Министерством строительства и жилищно-коммунального хозяйства Российской Федерации во исполнение постановления Правительства Российской Федерации от 10 февраля 2017 года № 169 «Об утверждении Правил предоставления и распределения субсидий из федерального бюджета бюджетам субъектов Российской Федерации на поддержку государственных программ субъектов Российской Федерации и муниципальных программ формирования современной городской среды»;

г) предварительное рассмотрение и согласование отчетов об исполнении Государственной программы, направляемых в Министерство строительства и жилищно-коммунального хозяйства Российской Федерации;

д) предварительное рассмотрение и согласование отчетов о реализации муниципальных программ, подготовленных муниципальными образованиями Республики Татарстан – получателями субсидии из бюджета Республики Татарстан, направляемых в Министерство строительства и жилищно-коммунального хозяйства Российской Федерации;

е) рассмотрение отчетов о ходе реализации Приоритетного проекта, подготовленных Премьер-министром Республики Татарстан, руководителями рабочих органов Республики Татарстан по Приоритетному проекту, органом исполнительной власти Республики Татарстан, ответственным за реализацию Приоритетного проекта.

4. Для осуществления вышеуказанных задач Комиссия выполняет следующие функции:

а) организует взаимодействие органов исполнительной власти Республики Татарстан, органов местного самоуправления муниципальных образований Республики Татарстан (далее – органы местного самоуправления), политических партий и движений, общественных организаций, объединений предпринимателей и иных лиц по обеспечению реализации мероприятий Приоритетного проекта или иных связанных с ним мероприятий;

б) взаимодействует с органами исполнительной власти Республики Татарстан, органами местного самоуправления, политическими партиями и движениями, общественными организациями, объединениями предпринимателей и иными лицами в части координации деятельности по реализации мероприятий Приоритетного проекта, в том числе в части обеспечения полноты и своевременности выполнения таких мероприятий;

в) анализирует отчеты о реализации муниципальных программ, подготовленные муниципальными образованиями Республики Татарстан – получателями субсидии из бюджета Республики Татарстан, отчеты об исполнении Государственной программы, направляемые в Министерство строительства и жилищно-коммунального хозяйства Российской Федерации,

и дает заключения по ним, а также иные материалы, связанные с реализацией Приоритетного проекта;

г) рассматривает вопросы выполнения Приоритетного проекта, в том числе осуществляет подготовку (участвует в подготовке) предложений по реализации Приоритетного проекта.

## III. Права Комиссии

5. Для осуществления возложенных на нее задач Комиссия вправе:

а) запрашивать в установленном порядке у органов исполнительной власти Республики Татарстан, органов местного самоуправления, а также организаций, предприятий, учреждений информацию в пределах своей компетенции по вопросам деятельности Комиссии;

б) приглашать на свои заседания представителей органов исполнительной власти Республики Татарстан, органов местного самоуправления, а также организаций, предприятий, учреждений;

в) вносить в органы исполнительной власти Республики Татарстан, органы местного самоуправления предложения по вопросам обеспечения реализации Приоритетного проекта;

г) согласовывать проект Государственной программы, в том числе рассматривать замечания и предложения по проекту Государственной программы, полученные при проведении общественного обсуждения указанного проекта;

д) совершать иные действия, связанные с реализацией Приоритетного проекта.

## IV. Организация работы Комиссии

6. В состав Комиссии входят председатель Комиссии, заместители председателя Комиссии, секретарь Комиссии и члены Комиссии.

7. Комиссию возглавляет председатель Комиссии – Президент Республики Татарстан.

8. Председатель Комиссии:

руководит деятельностью Комиссии;

председательствует на заседаниях Комиссии;

подписывает протоколы заседаний Комиссии;

выполняет иные функции в рамках своей компетенции, направленные на обеспечение выполнения задач Комиссии.

9. При отсутствии на заседании Комиссии председателя Комиссии его функции выполняет один из заместителей председателя Комиссии, определяемый председателем Комиссии.

10. Секретарь Комиссии:

организует подготовку заседаний Комиссии;

готовит материалы к заседаниям, необходимые для принятия решений Комиссии;

обеспечивает информирование членов Комиссии и иных заинтересованных лиц о дате, месте и времени проведения заседания Комиссии и о вопросах, включенных в повестку дня, в срок не позднее трех рабочих дней до дня проведения заседания Комиссии;

ведет протокол заседания Комиссии;

осуществляет иные полномочия, связанные с обеспечением работы Комиссии.

11. Члены Комиссии:

участвуют в заседании Комиссии;

выступают по вопросам повестки дня заседания Комиссии;

вносят предложения по рассматриваемым на заседании Комиссии вопросам.

12. Члены Комиссии обладают равными правами при обсуждении рассматриваемых на заседании вопросов.

13. Комиссия проводит заседания по мере необходимости, но не реже одного раза в квартал. В обязательном порядке на заседаниях Комиссии рассматривается вопрос реализации Государственной программы.

14. Кворум для проведения очных заседаний Комиссии составляет более половины числа членов Комиссии. В случае если на очном заседании кворум отсутствует, председатель Комиссии принимает решение о переносе заседания на другую дату.

15. Комиссия принимает решения по вопросам повестки заседания путем открытого голосования.

16. Решение Комиссии считается принятым, если за него проголосовало более половины членов Комиссии от числа принявших участие в заседании. Каждый член Комиссии при голосовании имеет один голос. При равенстве числа голосов решающим является голос председательствующего на заседании Комиссии.

17. Члены Комиссии вправе изложить в письменной форме особое мнение, которое подлежит отражению в протоколе и приобщается к материалам заседания Комиссии.

18. Решения Комиссии оформляются протоколом, который подписывается председателем Комиссии и секретарем, и размещаются на официальном сайте Министерства строительства, архитектуры и жилищно-коммунального хозяйства Республики Татарстан в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет» не позднее рабочего дня, следующего за днем подписания протокола.

19. Организационно-техническое и информационно-аналитическое обеспечение деятельности Комиссии осуществляет Министерство строительства, архитектуры и жилищно-коммунального хозяйства Республики Татарстан.

Приложение № 2
к Указу Президента
Республики Татарстан

от «29» мая 2017 года

№ УП-448

**Состав**
**Республиканской межведомственной комиссии**
**по обеспечению реализации приоритетного проекта «Формирование комфортной городской среды»**

| | |
|---|---|
| Минниханов Рустам Нургалиевич | Президент Республики Татарстан, председатель Комиссии |
| Песошин Алексей Валерьевич | Премьер-министр Республики Татарстан, заместитель председателя Комиссии |
| Файзуллин Ирек Энварович | министр строительства, архитектуры и жилищно-коммунального хозяйства Республики Татарстан, заместитель председателя Комиссии |
| Фролов Алексей Михайлович | первый заместитель министра строительства, архитектуры и жилищно-коммунального хозяйства Республики Татарстан, секретарь Комиссии |
| Абдулганиев Фарид Султанович | министр экологии и природных ресурсов Республики Татарстан |
| Гайзатуллин Радик Рауфович | министр финансов Республики Татарстан |
| Ганибаев Рифат Шагитович | председатель Татарской республиканской организации Всероссийского общества инвалидов – Общества инвалидов Республики Татарстан (по согласованию) |
| Здунов Артем Алексеевич | министр экономики Республики Татарстан |

| | |
|---|---|
| Корнилов<br>Марат Александрович | представитель Регионального отделения Общероссийского общественного движения «НАРОДНЫЙ ФРОНТ «ЗА РОССИЮ» в Республике Татарстан (по согласованию) |
| Метшин<br>Ильсур Раисович | глава муниципального образования города Казани (по согласованию) |
| Низамов<br>Рашит Курбангалиевич | ректор Казанского государственного архитектурно-строительного университета (по согласованию) |
| Ратникова<br>Римма Атласовна | заместитель Секретаря Татарского регионального отделения Всероссийской политической партии «Единая Россия» (по согласованию) |
| Романов<br>Дмитрий Сергеевич | исполнительный директор некоммерческого партнерства «Региональный Центр общественного контроля в сфере жилищно-коммунального хозяйства Республики Татарстан» (по согласованию) |
| Сафин<br>Ленар Ринатович | министр транспорта и дорожного хозяйства Республики Татарстан |
| Тимерзянов<br>Ренат Закиевич | главный федеральный инспектор по Республике Татарстан (по согласованию) |
| Фишман<br>Наталия Львовна | помощник Президента Республики Татарстан |
| Шакиров<br>Минсагит Закирович | председатель Совета муниципальных образований Республики Татарстан (по согласованию) |

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**«Шәһәрдә уңайлы мохит булдыру» өстенлекле проектын гамәлгә ашыруны тәэмин итү буенча республика ведомствоара комиссиясе турында**

Татарстан Республикасы территориясендә «Шәһәрдә уңайлы мохит булдыру» өстенлекле проектын гамәлгә ашыруны тәэмин итү, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына заманча шәһәр мохитен булдыру буенча Россия Федерациясе субъектлары дәүләт программаларына һәм муниципаль программаларга ярдәм итүгә субсидияләр бирү һәм аларны бүлү кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 10 февралендәге 169 номерлы карарын үтәү йөзеннән **карар бирәм**:

1. «Шәһәрдә уңайлы мохит булдыру» өстенлекле проектын гамәлгә ашыруны тәэмин итү буенча республика ведомствоара комиссиясе оештырырга.

2. «Шәһәрдә уңайлы мохит булдыру» өстенлекле проектын гамәлгә ашыруны тәэмин итү буенча республика ведомствоара комиссиясе турында нигезләмәне (1 нче кушымта) һәм аның составын (2 нче кушымта) расларга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

«Шәһәрдә уңайлы мохит булдыру» өстенлекле проектын гамәлгә ашыруны тәэмин итү буенча республика ведомствоара комиссиясе утырышларына материалларны үз вакытында әзерләүне тәэмин итәргә;

үз хокукый актларын әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аны гамәлгә ашыру өчен кирәкле башка карарлар кабул итәргә.

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы
Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2017 ел, 29 май
№ ПУ-448

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Татарстан Республикасы
Президентының
2017 елның « 29 » маендагы
ПУ- 448 номерлы Указына
1 нче кушымта

**«Шәһәрдә уңайлы мохит булдыру» өстенлекле проектын гамәлгә ашыруны тәэмин итү буенча республика ведомствоара комиссиясе турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. «Шәһәрдә уңайлы мохит булдыру» өстенлекле проектын гамәлгә ашыруны тәэмин итү буенча республика ведомствоара комиссиясе (алга таба – Комиссия) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына заманча шәһәр мохитен булдыру буенча Россия Федерациясе субъектлары дәүләт программаларына һәм муниципаль программаларга ярдәм итүгә субсидияләр бирү һәм аларны бүлү кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 10 февралендәге 169 номерлы карарын үтәү йөзеннән «Шәһәрдә уңайлы мохит булдыру» өстенлекле проектын (алга таба – Өстенлекле проект) үтәүнең барышын һәм Татарстан Республикасы территориясендә аны гамәлгә ашыруны координацияләүне контрольдә тоту өчен оештырылган ведомствоара коллегия органы булып тора.

2. Комиссия Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып эш алып бара.

## II. Комиссиянең төп бурычлары һәм функцияләре

3. Комиссиянең төп бурычлары түбәндәгеләр:

а) Өстенлекле проектны үтәүнең барышын контрольдә тотуны һәм Татарстан Республикасы территориясендә аны гамәлгә ашыруны координацияләүне башкару;

б) «Шәһәрдә уңайлы мохит булдыру» өстенлекле проектын гамәлгә ашыруны тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасы (алга таба – Дәүләт программасы) һәм заманча шәһәр мохите булдыру муниципаль программалары (алга таба – муниципаль

программалар), шул исәптән әлеге программалар нигезендә конкрет чаралар үтәлешен контрольдә тоту һәм координацияләүне башкару;

в) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына заманча шәһәр мохитен булдыру буенча Россия Федерациясе субъектлары һәм дәүләт программаларына һәм муниципаль программаларга ярдәм итүгә субсидияләр бирү һәм аларны бүлү кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 10 февралендәге 169 номерлы карарын үтәү йөзеннән Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы белән төзелгән килешү шартларын Татарстан Республикасы тарафыннан үтәлүен контрольдә тоту һәм координацияләүне башкару;

г) Дәүләт программасының үтәлүе турында Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына җибәрелә торган хисапларны алдан карап тикшерү һәм килештерү;

д) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре – Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр алучылар тарафыннан әзерләнгән, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына җибәрелә торган муниципаль программалар үтәлеше турындагы хисапларны алдан карап тикшерү һәм килештерү;

е) Татарстан Республикасы Премьер-министры, Өстенлекле проект буенча Татарстан Республикасы эш органнары җитәкчеләре, Өстенлекле проектны гамәлгә ашыру өчен җаваплы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан әзерләнгән Өстенлекле проектны гамәлгә ашыру барышы турында хисапларны карап тикшерү.

4. Алда атап кителгән бурычларны үтәү өчен Комиссия түбәндәге функцияләрне башкара:

а) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарының (алга таба – җирле үзидарә органнары), сәяси партияләр һәм хәрәкәтләрнең, иҗтимагый оешмаларның, эшкуарлар берләшмәләренең һәм башка затларның Өстенлекле проект чараларын һәм башка аның белән бәйле чараларны гамәлгә ашыруны тәэмин итү буенча үзара хезмәттәшлеген оештыра;

б) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, сәяси партияләр һәм хәрәкәтләр, иҗтимагый оешмалар, эшкуарлар берләшмәләре һәм башка затлар белән Өстенлекле проект чараларын гамәлгә ашыру буенча эшчәнлекне координацияләү өлкәсендә, шул исәптән мондый чараларның тулы күләмдә уздырылуы һәм үз вакытында башкарылуы өлкәсендә дә, хезмәттәшлек итә;

в) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре – Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр алучылар тарафыннан әзерләнгән муниципаль программалар үтәлеше турындагы, Дәүләт программасы үтәлеше турындагы Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына җибәрелә торган хисапларны анализлый һәм алар

буенча бәяләмәләр, шулай ук Өстенлекле проектны гамәлгә ашыру белән бәйле башка материаллар бирә;

г) Өстенлекле проектның үтәлеше мәсьәләләрен карап тикшерә, шул исәптән Өстенлекле проектны гамәлгә ашыру буенча тәкъдимнәр әзерләүне гамәлгә ашыра (әзерләүдә катнаша).

## III. Комиссиянең хокуклары

5. Үзенә йөкләтелгән бурычларны гамәлгә ашыру өчен Комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

а) Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, шулай ук оешмалар, предприятиеләр, учреждениеләрдән билгеләнгән тәртиптә үз компетенцияләре чикләрендә Комиссия эшчәнлеге мәсьәләләре буенча мәгълүмат соратырга;

б) үз утырышларына Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары, шулай ук оешмалар, предприятиеләр, учреждениеләр вәкилләрен чакырырга;

в) Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарына, җирле үзидарә органнарына Өстенлекле проектны гамәлгә ашыруны тәэмин итү мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр кертергә;

г) Дәүләт программасы проектын килештерергә, шул исәптән Дәүләт программасы проекты буенча әлеге проектны җәмәгатьчелектә тикшерүне уздыру вакытында алынган күрсәтмәләр һәм тәкъдимнәрне карарга;

д) Өстенлекле проектны гамәлгә ашыру белән бәйле башка гамәлләр кылырга.

## IV. Комиссия эшен оештыру

6. Комиссия составына Комиссия рәисе, Комиссия рәисе урынбасарлары, Комиссия секретаре һәм Комиссия әгъзалары керә.

7. Комиссияне Комиссия рәисе – Татарстан Республикасы Президенты җитәкли.

8. Комиссия рәисе:

Комиссия эшчәнлегенә җитәкчелек итә;

Комиссия утырышларында рәислек итә;

Комиссия утырышлары беркетмәләренә кул куя;

үз компетенциясе кысаларында Комиссия бурычларын үтәүне тәэмин итүгә юнәлтелгән башка функцияләр башкара.

9. Комиссия утырышында Комиссия рәисе катнашмаса, аның вазыйфаларын Комиссия рәисе билгеләве буенча Комиссия рәисе урынбасарларының берсе башкара.

10. Комиссия секретаре:

Комиссия утырышларын әзерләүне оештыра;

утырышларга Комиссия карарларын кабул итү өчен кирәкле материаллар әзерли;

Комиссия әгъзаларына һәм кызыксынган башка затларга, Комиссия утырышын уздыру көне, урыны һәм вакыты һәм көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр турында Комиссия утырышын уздыру көненә кадәр өч эш көненнән дә соңга калмыйча, хәбәр бирүне тәэмин итә;

Комиссия утырышы беркетмәсен алып бара;

Комиссия эшен тәэмин итү белән бәйле башка вәкаләтләрне башкара.

11. Комиссия әгъзалары:

Комиссия утырышында катнаша;

Комиссия утырышы көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр буенча чыгыш ясый;

Комиссия утырышында тикшерелә торган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр кертә.

12. Комиссия әгъзалары утырышта тикшерелә торган мәсьәләләр буенча фикер алышканда тигез хокукларга ия була.

13. Комиссия утырышлары кирәк булган саен, әмма ким дигәндә кварталга бер тапкыр уздырыла. Комиссия утырышларында Дәүләт программасын гамәлгә ашыру мәсьәләсе мәҗбүри төстә карап тикшерелә.

14. Комиссиянең утырышларын уздыру кворумын Комиссия әгъзалары санының яртысыннан артыгы тәшкил итә. Әгәр дә утырышта кворум булмаса, Комиссия рәисе утырышны башка датага күчерү турында карар кабул итә.

15. Комиссия ачык тавыш бирү юлы белән утырышның көн тәртибе мәсьәләләре хәл итү турында карарлар кабул итә.

16. Комиссиянең карары, әгәр аны хуплап утырышта катнашучы Комиссия әгъзаларының яртысыннан артыгы тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала. Тавыш бирү барышында һәрбер Комиссия әгъзасы бер тавышка ия була. Тавышлар саны тигез булганда, Комиссия утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

17. Комиссия әгъзалары үзләренең беркетмәгә теркәлергә тиешле аерым фикерен язмача бирергә хокуклы, ул Комиссия утырышы материалларына өстәп куела.

18. Комиссия карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә, аларга Комиссия рәисе һәм секретаре кул куя һәм алар, беркетмәгә кул куелган көннән соң килә торган эш көненнән дә соңга калдырмыйча, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура, торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

19. Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник һәм мәгълүмати-аналитик яктан тәэмин итүне Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура, торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы башкара.

Татарстан Республикасы
Президентының
2017 елның « 29 » маендагы
ПУ- 448 номерлы Указына
2 нче кушымта

**«Шәһәрдә уңайлы мохит булдыру» өстенлекле проектын гамәлгә ашыруны тәэмин итү буенча республика ведомствоара комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Миңнеханов Рөстәм Нургали улы | Татарстан Республикасы Президенты, Комиссия рәисе |
| Песошин Алексей Валерьевич | Татарстан Республикасы Премьер-министры, Комиссия рәисе урынбасары |
| Фәйзуллин Ирек Әнвәр улы | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры, Комиссия рәисе урынбасары |
| Фролов Алексей Михайлович | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрының беренче урынбасары, Комиссия секретаре |
| Габделганиев Фәрит Солтан улы | Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры |
| Гайзатуллин Радик Рәүф улы | Татарстан Республикасы финанс министры |
| Ганибаев Рифат Шаһит улы | Бөтенроссия инвалидлар җәмгыятенең Татарстан республика оешмасы – Татарстан Республикасы Инвалидлар җәмгыяте рәисе (килешү буенча) |
| Здунов Артем Алексеевич | Татарстан Республикасы икътисад министры |

| | |
|---|---|
| Корнилов<br>Марат Александрович | Татарстан Республикасында «РОССИЯ ӨЧЕН» ХАЛЫК ФРОНТЫ» гомумроссия иҗтимагый хәрәкәте төбәк бүлекчәсе вәкиле (килешү буенча) |
| Метшин<br>Илсур Рәис улы | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Низамов<br>Рәшит Корбангали улы | Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты ректоры (килешү буенча) |
| Ратникова<br>Римма Атлас кызы | «Бердәм Россия» бөтенроссия сәяси партиясе Татарстан төбәк бүлекчәсе Секретаре урынбасары (килешү буенча) |
| Романов<br>Дмитрий Сергеевич | «Татарстан Республикасы торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә җәмәгать контроле төбәк үзәге» коммерциячел булмаган партнерлыгы башкарма директоры (килешү буенча) |
| Сафин<br>Ленар Ринат улы | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры |
| Тимерҗанов<br>Ренат Зәки улы | Татарстан Республикасы буенча баш федераль инспектор (килешү буенча) |
| Фишман<br>Наталия Львовна | Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе |
| Шакиров<br>Минсәгыйть Закир улы | Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы рәисе (килешү буенча) |